Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

30 октябрь 2020 ел № 10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының XV бүлеге нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2020 елның 12 октябрендәге 1052 номерлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң

Әлмәт шәһәре Советы КАРАРЫ БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына тәкъдим ителгән үзгәрешләр проектын 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга:
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектын;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләрне әзерләү буенча комиссия составын;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен;
- 4 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты турында халык тыңлаулары үткәрү тәртибен.
5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты буенча халык тыңлауларын 2020 елның 01 декабренә 15.00 сәгатьтә Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының зур утырышлар залында үткәрүне билгеләргә (Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт, 325 нче бүлмә).

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә халык тыңлауларын уздыру турындагы Нигезләмә нигезендә комиссиягә Уставка үзгәрешләр проектын тикшерүне һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.

6. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының 15.1 статьясы, 18 статьяның 1, 2 өлешләре, 20 статьяның, 81 статьяның, 83.1 статьяның 2, 3, 5, 7 өлешләре белән кертелгән үзгәрешләр 2021 елның 01 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советының
2020 елның 30 октябрендәге
10 нчы санлы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты

1. 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18) участок полициясе хезмәткәре вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга торак урыны бирү»;

2. түбәндәге эчтәлекле 15.1 статья өстәргә:

«15.1 статья. Инициатив проектлар

1. Шәһәр халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә җирле үзидарә органнарына бирелгән мәсьәләләрне хәл итү хокукы җирле администрациягә инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган шәһәр территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе шәһәр Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Инициатив проектны кертү инициативасы белән уналты яшькә җиткән һәм тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче кимендә ун граждан булган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары (алга таба - проект инициаторлары) чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны шәһәр Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Проект инициаторы булу хокукы шәһәр Советының норматив хокукый акты нигезендә шулай ук шәһәр территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициатив проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблеманы тасвирлау;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнарның алдан исәпләве;

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында белешмәләр.

7) инициатив проектны гамәлгә ашыру күздә тотылган очракта яңа проектны гамәлгә ашыруга җирле бюджет средстваларын күрсәтү, планлаштырылган инициатицион түләүләрдән тыш;

8) инициатив проект гамәлгә ашырылача шәһәр территориясен яисә аның чикләрен шәһәр Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә күрсәтү;

9) шәһәр Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Инициатив проект аны җирле администрациягә керткәнче гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә

конференциясендә, инициатив проект турында фикер алышу, аның шәһәр халкы мәнфәгатьләренә туры килүен, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгын билгеләү, шулай ук инициатив проектны хуплау турында гражданнар җыелышы яисә конференциясе тарафыннан карар кабул итү максатларында каралырга тиеш. Шул ук вакытта гражданнарның бер җыелышында яисә бер конференциясендә берничә инициатив проект каралырга мөмкин.

Шәһәр Советының норматив хокукый акты белән шулай ук гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектка ярдәм итү мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклау мөмкинлеге карала.

Инициатив проектны җирле администрациягә керткәндә проектның инициаторлары аңа гражданнар җыелышының яисә конференциясенең беркетмәсен, гражданнардан сораштыру нәтиҗәләрен һәм (яисә) шәһәр халкы тарафыннан инициатив проектны хуплауны раслаучы имзалар кәгазьләрен беркетәләр.

5. Инициатив проектны җирле администрациягә кертү турындагы мәгълүмат инициатив проект җирле администрациягә кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерергә), муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш һәм әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләр булырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга үзләренең искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җирле администрациягә тапшыруның срогы һәм мөмкинлеге турында биш эш көненнән дә ким булмаган вакытта хәбәр ителә. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яшькә җиткән шәһәр халкы җибәрергә хокуклы. Шәһәр администрациясенең күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат составына шәһәр керә торган муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла.

6. Инициатив проект кертү көненнән алып 30 көн эчендә җирле администрация тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча җирле администрация түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә җирле бюджет проектын төзү һәм карау (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) тәртибе нигезендә тиешле максатларга һәм җирле бюджет турындагы карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә эшне дәвам итәргә;

2) инициатив проектка ярдәм итүдән баш тартырга һәм инициатив проектка ярдәм итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, проектны инициаторларына кире кайтарырга.

7. Җирле администрация инициатив проектка ярдәм итүдән баш тарту турында түбәндәге очракларның берсендә карар кабул итә:

1) инициатив проектны кертү һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шәһәр Уставы таләпләренә туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарында кирәкле вәкаләтләр һәм хокуклар булмау сәбәпле, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә җирле бюджет акчалары булмау, түләү чыганагы булып инициатив түләүләр барлыкка килмәгәндә;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проектны конкурс сайлавын узмаган дип тану.

8. Җирле администрация әлеге статьяның 7 өлеше 5 пунктында каралган очракта проект инициаторларына бергәләп инициатив проектны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы карамагына аларның компетенцияләре нигезендә тәкъдим итәргә хокуклы.

9. Инициатив проектларны күрсәтү, кертү, тикшерү, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру тәртибе шәһәр Советы тарафыннан билгеләнә.

10.Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициатив проектларга карата инициатив проектлар булырга тиешле белешмәләр составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 өлешләрендәге таләпләр кулланылмый.

11. Әгәр җирле администрациягә берничә инициатив проект кертелгән булса, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирланса, җирле администрация конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проектның инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә, аның формалаштыру һәм эшчәнлек тәртибе шәһәр Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә. Коллегиаль орган (комиссия) составы җирле администрация тарафыннан төзелә. Шул ук вакытта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми саныннан яртысы шәһәр Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проект инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль орган (комиссия) инициатив проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проектның инициаторлары, шәһәр территориясендә яшәүче гражданнар, гражданнар җыелышы яисә конференциясе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар инициатив проектны Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашыруны җәмәгать контролендә тотарга хокуклы.

14. Җирле администрация инициатив проектын карау, инициатив проектны гамәлгә ашыруның барышы, шул исәптән акча средстволарыннан файдалану, милек һәм (яки) аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның хезмәт катнашуы турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында җирле администрация хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң 30 календарь көн эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.»;

Шәһәр администрациясенең күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат составына шәһәр керә торган муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

3. 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:
1. «8. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.»;

4. 18 статьяга:

а) 1 өлештә «һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары,» сүзләреннән соң «инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре турында фикер алышу,» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициатив проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе шәһәр Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

5. 20 статьяда:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Гражданнардан инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда район халкы яисә уналты яшькә җиткән инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган өлеше катнашырга хокуклы.»;

б) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган гражданнар- район халкын яисә аның уналты яшькә җиткән өлеше әлеге инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау өчен.»;

в) 5 өлештә

- беренче абзацта «Шәһәр Советы. Карарда» сүзләрен «Шәһәр советы» сүзләренә алмаштырырга. Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кулланылырга мөмкин. Карарда";

- түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

г) 7 өлешнең 1 пунктына «яисә шәһәр халкы» сүзләрен өстәргә;

6. 59 статья түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы шәһәр Советы депутатына, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутаты, сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Шәһәр Советы карарлары белән билгеләнә.

2. Шәһәр Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру өчен, тулаем алганда аена алты эш көненнән дә артык булмаган чорда эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә

7. 81 статьяда:

а) 13 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 13.1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.1. Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм шәһәр Советына бюджет турында карар кертелгәннән соң кабул ителгән шәһәр Советының муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка агымдагы финанс елына һәм план чорына үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында исәпкә алына.»;

8. түбәндәге эчтәлекле 83.1 статья өстәргә:

«83.1. Инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан һәм башкача тәэмин итү

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясында каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, муниципаль берәмлекнең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан инициатив түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып, инициатив проектларны гамәлгә ашыруга җирле бюджет турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре тора.

2. Инициатив түләүләр дигәндә, конкрет инициатив проектларны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле нигездә түләнә торган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетка күчерелә торган гражданнарның, индивидуаль эшкуарларның һәм юридик затларның акчалары аңлашыла.

3. Инициатив проект гамәлгә ашырылмаган очракта, инициатив түләүләр аларны җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча инициатив проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмаган инициатив түләүләрнең калган өлеше барлыкка килгән очракта, күрсәтелгән түләүләр аларны җирле бюджетка күчергән затларга (шул исәптән оешмаларга) кайтарылырга тиеш.

Җирле бюджетка күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициативалы түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе шәһәр Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициативалы проектларны тормышка ашыру, шулай ук, кызыксынган затларның ирекле мөлкәти һәм (яки) хезмәт катнашуы рәвешендә дә тәэмин ителергә мөмкин».

Шәһәр Башлыгы

Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советының
2020 елның 30 октябрендәге
10 нчы санлы карарына 2 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссия СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Баһманов И.Р. | Әлмәт шәһәре башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| 2. | Парфилова Н.В. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәре Советы депутаты |
| 3. | Мусин Р.Ф. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты, бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 4. | Шәйхетдинова Ф.М. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе |
| 5. | Закиров Р.З. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты |
| 6. | Әфләтунова Р.Е. | Әлмәт муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| 7. | Ханнанова Ә.Б. | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хокук идарәсе җитәкчесе |

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советының
2020 елның 30 октябрендәге
10 нчы санлы карарына 3 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның катнашуы һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. 1. Әлеге тәртип 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы нигезендә эшләнгән һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә катнашуын һәм аларның тәкъдимнәрен исәпкә алуны билгели.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты буенча тәкъдимнәр Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советына язма рәвештә, кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кертелә:

| №№ п/п | Пункт, подпункт | Проект тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмә исәпкә алынган проект тексты | Нигезләмә | Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны, имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 дән 17 сәгатькә кадәр Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты «Альметьевский вестник» газеталарында басылган көннән соң 20 көн дәвамында кабул ителә.

3. Халык тыңлауларында катнашу өчен заявкалар шәхсән яки почта аша (конвертка «Уставны тикшерү» дип языла) Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 нчы йорт адресы буенча, шулай ук 39-01-31 факсы буенча, халык тыңлауларын үткәрү көненә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре һәм чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашуга заявкалары Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының хатлар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм тикшерү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссиягә тапшырыла.

5. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектында булган үзгәрешләргә карата гына кертелә һәм федераль законнар таләпләренә туры килергә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының башка нигезләмәләренә каршы

килмәскә яисә алар белән килешмәвенә юл куелмаска һәм шәһәр Уставы нигезләмәләренең бер мәгънәдә генә аңлатылуын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге тәртиптә күздә тотылган тәртипне, форманы һәм срокларны бозып кертелгән тәкъдимнәр комиссия карары буенча тикшерелмичә калдырылырга да мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты, шулай ук гражданнарның халык тыңлауларына чыгарылган тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә халык тыңлауларын уздыру турындагы Нигезләмә нигезендә халык тыңлауларында тикшерүгә чыгарыла

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәр Советының
2020 елның 30 октябрендәге
10 нчы санлы карарына 4 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты турында халык тыңлауларын үткәрү тәртибе

1. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проекты буенча халык тыңлаулары 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 28 нче маддәсе, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә халык тыңлауларын үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы проекты һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты аны кабул итү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы тарафыннан каралачак көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Бер үк вакытта әлеге проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча халык тыңлауларын билгеләү турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы карары да бастырып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы шәһәре Уставын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында аңа Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлаучы үзгәрешләр кертелгән очракта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы шәһәр Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару таләп ителми.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Уставын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында аңа Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгән очраклардан кала, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы проекты буенча яки Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча халык тыңлаулары Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставында билгеләнгән срокларда үткәрелә.

4. Халык тыңлауларын үткәрү турында карар басылып чыккан көннән алып аларны үткәрү көненә кадәр районда яшәүчеләр халык тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәрен, искәрмәләрен һәм төзәтмәләрен җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән тәкъдимнәр, искәрмәләр һәм төзәтмәләр халык тыңлауларында катнашучылар игътибарына җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы

проекты яки Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советы карары нигезендә халык тыңлаулары үткәрү буенча вәкаләтле орган булып комиссия тора.

6. Халык тыңлауларында шәһәр башлыгы, шәһәр Башлыгы урынбасары, шәһәр Советының даими комиссияләре рәисләре рәислек итә ала. Рәислек итүче халык тыңлауларын ача, халык тыңлаулары соравын (сорауларын), тыңлаулар үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, тыңлауларны үткәрү инициаторларын күрсәтә.

7. Рәислек итүче халык тыңлауларын үткәрү инициаторлары тарафыннан вәкаләтле итеп сайланган затка, шулай ук халык тыңлауларында чыгыш ясарга хокукы булган катнашучыларга сүз бирә. Чыгышларның чират тәртибе комиссия тарафыннан теркәлгән гаризалар чираты буенча билгеләнә.

8. Тыңлауларда катнашучылар халык тыңлауларында башка катнашучылар тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәргә кушылырга һәм (яки) үз рекомендацияләрен кире алырга хокуклы.

9.Халык тыңлаулары вакытында беркетмә алып барыла. Халык тыңлауларында катнашучыларның тыңлаулар барышында керткән барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре халык тыңлаулары секретарена юллана.

10. Беркетмә халык тыңлауларында рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советында саклана.

11. Халык тыңлаулары беркетмәсе нигезендә, халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 3 эш көне эчендә, халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында заключение төзелә.

12. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм халык тыңлаулары уздырылган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов